**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.01.2022 **Чирмешән авылы** №460

**«2023 елда Чирмешән муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклandыруны оештыру турында»**

«Мәгариф турында» 273 номерлы ФЗ, ТР МКның «2023 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» 2022 елның 1 сентябрендәге 934 номерлы, «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларга түләүсез кайнар ризыкны оештыру һәм тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем программалары буенча укучыларга кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында» 2022 елның 14 июлендәге 991 номерлы ТР МК карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 3 октябрендәге 1065 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Районның гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 1-11 сыйныф укучыларын кайнар аш белән тәэмин итәргә.

2. Районның гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

2.1. Уку чорында муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны тукландыруны 5-11 сыйныфларның һәр баласына көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидия һәм ата-аналарның туклануга ирекле иганәсе исәбенә оештырырга.

2.2. 2023 елда районның гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч сыйныф укучылары өчен бер балага көненә 64 сум 19 тиенгә түләүсез кайнар аш оештырырга.

2.3. Методик рекомендацияләр нигезендә ата-аналар белән эшне оештырырга һәм район мәгариф оешмаларында укучыларның туклану сыйфатын контрольдә тоту буенча мәктәп комиссияләре төзергә.

2.4 СанПин нормалары һәм 22.03.2022 елда сатып алу буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль заказчылар тарафыннан азык-төлек продуктларын кабул итү регламенты" нигезендә азык-төлек продуктларын кабул итүне оештырырга.

3. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә кайнар туклануны оештыру сыйфаты, иминлеге өчен җаваплылык йөкләргә.

4. Районның гомуми белем бирү оешмаларында кайнар туклануны оештыруны

тикшереп тору буенча район комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесенең беренче урынбасары И.Н. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
16.12.2022 №460

**Гомуми белем бирү оешмаларында кайнар ашны оештыруны тикшереп тору буенча район комиссиясе составы.**

| | |
|---|---|
| Рәис: | - Шәйдуллин И.Н. – ТР Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Комиссия әгъзалары: | - Хөбәтуллина З.М. - Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе |
| | - Ханова Д.Д. – Чирмешән муниципаль районының ата-аналар комитеты рәисе (килештерү буенча) |
| | - Муксинова Л.В. – Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| | - Маркова О.В. – «Мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе |
| | - Рәхимҗанова Ф.М. – «Мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе урынбасары |
| | - Вафина Г.В. – «Мәгариф бүлеге» МКУ методист-психологы |
| | - Серова Л.Ф. – «Мәгариф бүлеге» МКУ методисты |
| | - Нурисламова Г.Р. - «Мәгариф бүлеге» МКУ методисты |